| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОКЫРЛАЙСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,<br>Арский муниципальный район, 422035 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА КЫРЛАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,<br>Арча муниципаль районы, 422035 |

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru


**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**22.09.2017 ел** **№42**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2018 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | - авыл җирлеге торак пунктларының юл-урам челтәренә вак таш сатып алу, нигез һәм юл өслеге салу буенча хезмәтләр күрсәтү:<br>Яңа Кырлай авылы, Яшьләр ур., Яшел ур., Дуслык ур., Татарстан ур.;<br>Яңа Иябаш авылы Татарстан ур., Яшьләр ур.;<br>Өчиле авылы Тукай урамы, Җиңүнең 65 еллыгы ур.;<br>Чиканас авылы Совет ур., Октябрь ур. ;<br>Иске Юрт авылы Аркылы ур., Клуб ур.;<br>Югары Бирәзә авылы Ленин ур., Бахча-Сарай ур., Пәшкәү ур.;<br>Күкчә-Бирәзә авылы Аркылы ур., Тынычлык ур. |

Әйе Юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күплəп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай ур., 73 йорт.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012702